Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге составына керүче Благодатная торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елның 13 октябрендә № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлегенең Благодатная торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлегенең Благодатная торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче солдатлардан, ирегеннән мәхрүм ителгән гражданнардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, тормыш иптәшләреннән тыш, 1000 сум күләмендә гражданнарның үзара салым салу чараларын кертергә/Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның хатыны, эшләмәүче пенсионерлар 50% күләмендә түләү башкаралар.
2. Алынган акчаларны биха-Юсич урамындагы суүткәргеч өчен артезиан скважинасын бораулауга юнәлтергә.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлегенең Благодатная торак пунктында гражданнар Җыенының 04.11.2022 ел №4 карары нигезендә җыелган 456 608 сум күләмендә гражданнарның үзара салым салу чараларының калдыгы, Тынычлык урамындагы 15 нче йорттан 71 нче йортка кадәр суүткәргечне ремонтлауга һәм Заречная урамындагы 1 нче йорттан 8 нче йортка кадәр суүткәргечне ремонтлауга (килешү буенча), Юность урамындагы 30 нчы йорттан Тынычлык урамына кадәр 44/1 нче йортка кадәр юлны бетондаштыруга җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сосновка авыл җирлеге башлыгы А.Н.Бурчин